**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» февраля 2021 с. Тюлячи № 33

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 24 апрелендәге 398 номерлы «Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына (алга таба - карар) (27.01.2014 № 43, 18.02.2016 № 91, 08.11.2016 № 1012, 11.07.2017 № 422, 23.10.2019 № 590 карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертергә, кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2012 елның 24 апрелендәге
398 номерлы

«Хөкем ителүчеләрнең төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү урыннарын билгеләү турында» карарына кушымта

| Объект атамасы | Эш төрләре |
|---|---|
| 1. Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>2. Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>3. Теләче муниципаль районы Алан | - торак пунктлар территорияләрен җыештыру, яшелләндерү, төзекләндерү;<br>- эш биналарын (административ биналарны) җыештыру;<br>- төяү-бушату эшләре; |

| | |
|---|---|
| авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>4. Теләче муниципаль районы Баландыш авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>5. Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>6. Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>7. Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>8. Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>9. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>10. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>11. Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>12. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге башкарма комитеты.<br>13. Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге башкарма комитеты | - биналар, корылмалар, юллар ремонт (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр |
| 14. ДБУ «Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы».<br>15. ДБУ «Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» | - урман кисү урыннары (визирлар кисү, баганалары ясау һәм урнаштыру);<br>- яшь үсентеләрне карау (яктырту, чистарту);<br>- урман фонды территорияләрен төзекләндерү ,урман кишәрлекләрен санкцияләнмәгән җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын тәртипләү, беседкалар урнаштыру, ауган агачларны җыештыру һ.б.);<br>- урман культуралары җитештерү (Колесов җайланмасы белән агач утырту, агач утырту машинасы артыннан үсентеләр биреп бару, урман утырту машинасы артыннан үсентеләр бирү, урман культураларын тулыландыру, урман культуралары мәйданнарын табигый бизәгәндә баганалар әзерләү һәм урнаштыру, |

| | |
|---|---|
| | урман культураларын агротехник яктан тәрбияләү);<br>- авиация һәм җир өсте ысуллары белән зарарлы организмнар учакларын локальләштерү һәм бетерү эшләрен башкарганда агрегатларга эш эретмәләре белән ягулык салу;<br>- урман янгыннарын җир өсте юлы белән сүндерү |
| 16. «АгроЛак» ҖЧҖ.<br>17. «Алан» ҖЧҖ.<br>18. «Игенче» ҖЧҖ.<br>19. «Август-Теләче» ҖЧҖ.<br>20. «Зиннатуллин Р.А.» ШЭ.<br><br>21. «Кряж» ҖЧҖ.<br>22. «Тукаш» ҖЧҖ.<br><br><br><br><br><br><br>23. ШЭ Мифтахов Н.Р.<br>24. «Авангард-Строй» ҖЧҖ | - территорияләрне җыештыру;<br>- төяү-бушату эшләре;<br>- биналар, корылмалар, юллар ремонт (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр;<br>- төяү-бушату эшләре;<br>- территорияләрне җыештыру;<br>- биналар, корылмалар, юллар ремонт (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр;<br>- линия операторы;<br>- төяү-бушату эшләре;<br>- территорияләрне җыештыру;<br>- биналар, корылмалар, юллар ремонт (төзелеш) эшләрен башкарганда ярдәмче эшләр;<br>- биналарны, корылмаларны, юлларны карап тоту эшләре |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин